ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

07.03.2025
466

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган күчемсез һәм күчемле мөлкәт өчен бүлеп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм арендага алынган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның 2022 елның 14 декабрендәге 268-ПР номерлы йөкләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган күчемсез һәм күчемле мөлкәт өчен бүлеп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен сигез ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.

2. Арендага алынган күчемсез һәм күчемле мөлкәт өчен түләү тәртибен (бер тапкыр яки бүлеп түләү) һәм әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә бүлеп түләү срогын сайлау хокукы арендага алынган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яки урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган күчемсез һәм күчемле мөлкәт өчен бүлеп түләү срогын билгеләү турында»» 2024 елның 24 маендагы 694 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева